КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 сентябрь г.Казань № 847

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 август, 687 нче; 2020 ел, 2 сентябрь, 774 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта «балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре» сүзләрен төшереп калдырырга, «100» саннарын «200» саннарына алыштырырга;

6 нчы пунктта:

«ж» пунктчасында:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «50» саннарын «70» саннарына алыштырырга;

алтынчы абзацта «100» саннарын «200» саннарына алыштырырга;

җиденче абзацта «50» саннарын «100» саннарына алыштырырга;

«к» пунктчасында «50» саннарын «70» саннарына алыштырырга;

«л» пунктчасында «50» саннарын «70» саннарына алыштырырга;

«м» пунктчасында:

икенче абзацта «100» саннарын «200» саннарына алыштырырга;

өченче абзацта «50» саннарын «100» саннарына алыштырырга;

«н» пунктчасында «50» саннарын «70» саннарына алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «о» пунктчасын өстәргә:

«о) 2020 елның 21 сентябреннән Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә алдан язма хәбәрнамә җибәрү һәм бүлмәдә бер үк вакытта булырга мөмкин булган затларның әлеге бүлмә мәйданының 4 кв.метрына бер кеше (хезмәткәрләрне кертеп) исәбеннән билгеләнә торган иң чик санына карата таләпләрне үтәү шарты белән балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре эшләве.»;

7 нче пунктта:

беренче абзацның җөмлә башына татар текстында «65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга,» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән бер көн үткәч үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин